# Алар исән-сау кайттылар

## Нурмөхәммәтов Мулла Нурмөхәммәт улы

Сугышка 1941елның август аенда китә. Ленинград өчен барган авыр сугышта катнаша. " Ленинград оборонасы өчен", юбилей медале белән бүләкләнә.

## Каримуллин Гинияят

_1941 елнын 4 декабрендә сугышка алганнар. 53 нче гвардия миномёт полкында була. 1942 елны Карелия фронтының 19 нчы армиясендә хезмәт итә.
Карелиядә сугыш беткәч, аларны икенче Украина фронтына кучергәннәр. Шуннан сон Мәскәугә алып кайтканнар. Мәскәүдә 1945 елның 24 январь аеннан 12 июньгә кадәр була. Аннан соң аларны Көнбатышка җибәрәләр.Сугышны Кытай җирендә тәмамлый. Бик күп Хөкүмәт бүләкләренә лаек була.

## Нигъматуллин Хәмәт

1938 елда хезмәт итәргә китә. Шуннан сугышка җибәрәләр. Варшава , Познань, Берлин шәһәрендә була.
Буләкләре: «За боевые заслуги», Сталиннын 6 рәхмәт хаты – Берлинны алган өчен, Варшаваны азат иткән өчен.

## Шаймарданов Хажи

1941 елның июнендә сугышка китә. Ул авыр артилериядә хезмәт итә. Белоруссиядә, Чехословакиядә сугышкан. 1943 елда Ленинградта яралана . «За боевые заслуги», «За отвагу»дигән медале, Сталиннан 6 рәхмәт хаты алган.

## Нигъматуллин Хәмәт

1938 елда хезмәткә китә. Шуннан сугышка җибәрәләр. Варшава , Познань, Берлин шәһәрендә була.

Бүләкләре: «За боевые заслуги», Сталиннын 6 рәхмәт хаты – Берлинны алган өчен, Варшаваны азат иткән өчен.

## Садыков Фоат Шахмиссарович

Фоат Шахмиссарович 1941 нче елда сугышка китә. Башта гади сугышчы, аннан замполит була. Муса Җәлил укыган Минзәлә курсларында белем күтәреп, лейтенант исеме ала. Мәскәу астында, Карелия фронтында комиссар булган.

## Сафиуллин Габдулла.

Ул 1942 елның 23 августында сугышка китә. Төньяк флотта рядовой була. 1947 елның 27 мартында туган якка әйләнеп кайта.

Бүләкләре: "Орден Красной Звезды», юбилей медале.

## Зиннатов Шәрифулла

1941 елда сугышка китә. Шәрифулла абый Сталинград фронтында, Курск дугасында сугышкан. Сугышта яраланып ,2 группа инвалид булып кайткан.

## Сәлимгәрәев Асылгәрәй

Бөек Ватан сугышында катнаша. Артилерист була. Ленинград блокадасында яралана.

## Галимов Дәхи

Галимов Дәхи абый сугышка 1941 елнын 14 нче июне көнне өеннән чыгып китә. Ул беренче Украина сугышында катнаша. 3 тапкыр яралана. " Батырлык өчен", " Чехословакияне азат итү өчен" медале белән бүләкләнә.

## Абзалов Хади

_Абзалов Хади абый 1942 елның декабрь аенда сугышка китә. Ул Төньяк- Көнбатыш фронтында була. Ярославль областенда барган сугышта катнаша һәм каты яралана.Хади абыйның Хөкүмәт тарафыннан бирелгән бүләкләре күп.

## Шаймарданова Мухлиса

1942 елда сугышка китә. Смоленский , Белоруссия , Варшава өчен барган канлы сугышта катнаша. Хөкүмәт тарафыннан бирелгән бүләкләре бар.